СОВЕТ НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**

**№ 14** **22.01.2026 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы 2019 елгы 15 ноябрендәге 114 номерлы «Җир салымы турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында ( 16.11.2020 ел № 11, 25.05.2021ел № 27, 15.12.2023ел № 74, 16.12.2024ел № 93 үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә һәм «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 ел 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы КАРАРы::

1. Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы 2019 ел 15 ноябрендәге 114 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә::
"- махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар:
- Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм полициянең махсус исемнәре булган затлар, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре;
-ирекле формированиедә булу турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә яисә Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында) контракт төзегән йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) гражданнар;
- махсус хәрби операция үткәрү чорында Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүче (башкаручы) затлар:
Россия Федерациясе Тикшерү комитеты, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәте, Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары хезмәткәрләре;
Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре;
прокурор хезмәткәрләре;
- Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм махсус полиция исемнәре булган затлар, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре, махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга якын участокларда Федераль куркынычсызлык хезмәте органнарына ярдәм күрсәтү бурычларын үтәүче (башкаручы) ;
- гаилә әгъзалары:
әлеге пунктның 5-6 абзацларында күрсәтелгән затлар;

Россия Федерациясе Коралды Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;
махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) хәрби хезмәткәрләр;
махсус хәрби операция үткәрү чорында Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүче (башкаручы) Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының коткару хәрби формированиеләре хәрби хезмәткәрләре;
Федераль иминлек хезмәте органнарының махсус хәрби операция уздыру районнарына якын участокларда Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итү бурычларын турыдан-туры үтәүче (башкаручы) хәрби хезмәткәрләре;
махсус хәрби операция уздыру районнарына якын участокларда Федераль куркынычсызлык хезмәте органнарына ярдәм күрсәтү бурычларын үтәүче (башкаручы) Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре хәрби хезмәткәрләре;
Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә дислокацияләнгән (урнашкан) хәрби частьләрдә, органнарда, оешмаларда, учреждениеләрдә һәм бүлекчәләрдә контракт буенча хәрби хезмәт узучы йә вакантлы хәрби вазыйфалар буенча вазыйфаларны вакытлыча башкару өчен кимендә өч айга җибәрелгән (командировкага җибәрелгән) Федераль иминлек хезмәте органнарының, дәүләт саклау органнарының хәрби хезмәткәрләре бу хәрби частьларда, органнарда, оешмаларда, учреждениеләрдә һәм бүлекчәләрдә;

- гаилә әгъзалары:

әлеге пунктның 5 һәм 6 абзацларында күрсәтелгән затлар, "ветераннар турында" 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 пунктының 2_3 һәм 9 пунктчалары нигезендә сугышчан хәрәкәтләр ветераннарына караган затлар. Һәлак булучылар исәбенә шулай ук хәрби хезмәттән азат ителгән (хезмәттән азат ителгән, хезмәт шартнамәсе яисә башка хокук мөнәсәбәтләре туктатылган) көннән алып бер ел узганчы, махсус хәрби операция үткәрү чорында (махсус хәрби операция үткәрү чорында бурычларны үтәгәндә) алган гарипләк (яралану, җәрәхәтләнү, контузия)яисә авыру нәтиҗәсендә вафат булган затлар керә.;

2014 елның 11 маеннан Донецк Халык Республикасы Коралды Көчләре, Луганск Халык Республикасы халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында хәрби хәрәкәтләрдә катнашуга бәйле рәвештә һәлак булган (вафат булган) затлар"

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

3.Карарны Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru".

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: Макаров А.В.